ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2025 г. Казань № 717-5/соц-2025

Татарстан Республикасында «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 - 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 13.02.2021 ел, №77, «2026 елга «Сиделка» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башына финанслау нормативы турында» 20.12.2025 ел, №1116 карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 26.12.2025 ел, №36-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән алып 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
26.12.2025 № 717-5/соц-2025
карарына кушымта

## «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтүгә тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | «Карау буенча ярдәмче» хезмәтен күрсәтү | сум/сәгать | 404,02 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге